Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамал авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 11 феврале № 95

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 46 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге 46нчы номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партиядә,» сүзеннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71;

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы,Ленин урамы, 61 нче йорт, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы рәисе Х.Х. Ибатов